| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>САХАРОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>САХАРОВКА АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**19.02.2025** **№ 40**

**2012 елның 24 декабрендәге 66 номерлы «Коррупциягә каршы көрәш максатларында билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу турындагы таләпләрне һәм бурычларны үтәмәгән өчен түләтүләр куллану тәртибе турындагы Нигезләмә хакында» карарга үзгәрешләр кертү турында**

"Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында"2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законга туры китереп

**Сахаровка авыл җирлеге Советы карар бирде:**

1. Сахаровка авыл җирлеге Советының 2012 елның 24 декабрендәге 66 номерлы «Коррупциягә каршы көрәш максатларында билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны,мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу турындагы таләпләрне һәм бурычларны үтәмәгән өчен түләтүләр куллану тәртибе турындагы Нигезләмә хакында» карары белән расланган коррупциягә каршы көрәш максатларында билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны,мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу турындагы таләпләрне һәм бурычларны үтәмәгән өчен түләтүләр куллану тәртибе турындагы Нигезләмәнең 7 пунктындагы 1 пунктчасын «яисә «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13_4 статьясы нигезендә Россия Федерациясе Президенты администрациясенең вәкаләтле бүлекчәсе тарафыннан» сүзләре белән тулыландырырга.
2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (https://alekseevskiy.tatarstan.ru/), Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзартымда калдырам.

**Сахаровка авыл җирлеге Советы**
**утырышында рәислек итүче,**
**1 нче сайлау округы депутаты Н.И. Леденцов**